САУЛЫК КАДЕРЕ
Республика балалар клиник хастаханәсенең онкогематология үзәгендә ике меңнән артык сабый дәваланган
> 2

ӨЙ КОРГАН УҢАР
Йорт салучыларга дәүләт тә булыша
> 2

ҖИРГӘ ТӨШҮ
«Рубин»да бер елдан премьер-лигага әйләнеп кайтырга хыялланалар
> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА
Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 78 (28851) | Шимбә | 4 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

САНАЛДЫК
ҖАНИСӘПНЕҢ БЕРЕНЧЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ БИЛГЕЛЕ

Республика халкы шәһәрдә яшәүне өстенрәк күрә. Ник дигәндә, соңгы ун елда Татарстанда авылдан шәһәргә күченүчеләр арткан. Дистә ел вакыт эчендә республикада яшәүчеләр дә күбәйгән. Татарстан хәтта бу күрсәткеч буенча Идел буе төбәкләре арасында беренче урынга ук чыккан. Узган елның көзендә үткән илкүләм халык санын алуның беренче нәтиҗәләре әнә шуннан гыйбарәт.

Эшсез булмый

Бу көннәрдә Росстат идарәсе узган елның 15 октябреннән 14 ноябренә кадәр дәвам иткән илкүләм халык санын алуның беренче нәтиҗәләрен игълан итте. Белгечләр китергән саннардан аңлашылганча, бүген Россиядә 147,19 миллион кеше яши. Бу, 2010 ел күрсәткечләре белән чагыштырганда, 5 миллионга күбрәк. Белгечләр илдәге халык саны Кырымның Россия составына кертелүе, читтән күченеп килүчеләр саны хисабына арткан дип ышандыра.

Тагын да төгәлрәк саннарга күчсәк, халыкның артуы илнең 28 төбәгендә генә күзәтелә. Бу күрсәткеч буенча беренче өчлеккә Мәскәү өлкәсе (1,5 миллион кешегә арткан), Мәскәү (1,4 миллион), Санкт-Петербург (826 мең) шәһәрләре эләккән. Краснодар краенда, Төньяк Кавказда яшәүчеләр саны да арткан. Халык саны кимүнең иң зур күрсәткече – Ерак Көнчыгышта. Соңгы ун елда биредәге халык 5 процентка азайган. Шул вакыт эчендә Себердә (2,2 процент), Алтай краенда (229,4 мең) яшәүчеләр саны да кимегән. Сүз уңаеннан, соңгы дистә елда Россиядә миллион кеше яшәгән шәһәрләр саны да арткан. Җанисәп нәтиҗәләреннән күренгәнчә, Краснодар, Красноярск, Воронеж һәм Пермь шәһәрләре дә хәзер шушы сафта.

Социология фәннәре докторы Виктор Левашов төбәкләрдәге халык саны үзгәрешенә аптырарга кирәкми дигән фикердә. «Халык икътисади яктан үсеш алган, яңа җитештерүләр булдырылган төбәкләргә тартыла. Мәскәүдә, әйтик, эшмәкәрлек алга киткән, нәтиҗәдә эш урыннары да җитәрлек. Шуңа күрә күпчелек халык шунда агыла. Халык саны кимегән төбәкләрне исә бер проблема берләштерә. Ул да булса – эшсезлек. Эш булмаган җирдә халыкны, бигрәк тә яшьләрне тотып булмый», – ди белгеч.

Идел буе төбәкләрендә халык саны ничек үзгәргән?

Төбәк исеме	2010	2021	Үсеш
Татарстан	3786	4005	+5,8%
Башкортстан	4072	4091	+0,5%
Самара өлкәсе	3215	3172	-1,3%
Мари Иле	696	677	-2,7%
Саратов өлкәсе	2521	2443	-3,1%
Пермь крае	2635	2532	-3,9%
Удмуртия	1521	1453	-4,5%
Чувашия	1251	1187	-5,2%
Түбән Новгород	3310	3119	-5,8%
Мордовия	834	784	-6,1%
Ульяновск	1292	1197	-7,4%
Оренбург	2033	1863	-8,4%
Пенза	1386	1266	-8,7%
Киров	1341	1154	-13,9%

Шәһәр үзенә тарта

Соңгы ун елда Идел буе төбәкләрендә дә халык санының кимүе күзәтелә (таблица. – **Д.Г.**). Дистә ел вакыт эчендә Татарстан белән Башкортстанда яшәүчеләр саны гына арткан. Төгәлрәк әйтсәк, ун ел эчендә Татарстанда яшәүчеләр саны 5,6 процентка артып, 4 миллион 5 мең кешегә җиткән. Белгечләр моны бик зур күрсәткеч дип бәяли. Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге җитәкчесе, социология фәннәре докторы Чулпан Илдарханова сүзләренә караганда, моңа кадәр республикада мондый күрсәткечнең күзәтелгәне булмаган.

– Бу күренешне демографик чәчәк ату дип бәяләргә мөмкин. Республикада яшәүчеләр санының беркайчан да 4 миллионнан артканы булмады. Татарстанда халык санының максималь күрсәткече 2020 елда теркәлде. Ул чакта республикада яшәүчеләр саны 3902888 кеше тәшкил итә иде. Әмма ковид аркасында аларның саны 8768 кешегә кимеде. Шул рәвешле 2021 ел башына Татарстанда яшәүчеләр саны 3894120 кешегә калды, – дип сөйләде белгеч «ВТ» хәбәрчесенә.

Чулпан Илдарханова сүзләренә караганда, Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге белгечләре, 2018 ел башына булган халык саны күрсәткечләре буенча, 2033 елга Татарстан халкы 4040183 кешегә кадәр җитәр, дип фаразлаган булган. Әмма 2022 елгы саннар аркасында бу фаразга төзәтмә кертергә туры килгән. «Халык санының нәрсә хисабына артуын 2023 елда Росстат сайтында җанисәпнең тулы нәтиҗәләре басылгач кына төгәл әйтеп булачак», – ди Чулпан Илдарханова.

Соңгы ун елда республика халкы авылга караганда шәһәрдә яшәүне дә өстенрәк күрә башлаган. Ун ел эчендә Татарстанда авылдан калага күченүчеләр саны 1,4 процентка арткан. Шул рәвешле бүген республикада яшәүчеләрнең 3,074 миллионы – шәһәр халкы, 931 мең кеше авылда яши. Башкортстан Республикасы, Пенза, Саратов, Ульяновск, Киров өлкәләрендәге авылларда да халык саны шундый зур тизлек белән кими, ди белгечләр. Ә менә Удмуртия белән Самара өлкәсендә вазгыять башкачарак. Биредә, киресенчә, шәһәрдән авылга күченүчеләр күбрәк.

Җанисәпнең беренче нәтиҗәләрендә ил халкының яше, милләте, җенесе турында мәгълүматлар юк. Росстат белгечләре халык санын алуның тулырак йомгакларын ел азагында игълан итәргә җыена.

Якутиядә – Татарстан скверы

Якутск шәһәрендә Татарстан скверы пәйда булачак. Республика вице-премьеры, «Милли шура» советы рәисе Васил Шәйхразыев Якутиягә сәфәре барышында булачак сквер урынын караган. Аңа тәүге нигез ташы 23–25 июньдә, Татарстан көннәрендә салыначак. Чара Саха (Якутия) Республикасына 100 ел тулуга багышлап уздырыла.

Татарстан көннәре кысасында Татар киносы көннәре, «Татармультфильм» берләшмәсенең электрон күргәзмәсе, сәнгать осталары концертлары, кәсепчелек әйберләре күргәзмәсе, Буа дәүләт драма театры гастрольләре, «Татарларда кунакта» күчмә күргәзмәсе оештырылачак. Моннан тыш якут халкының Ысыах бәйрәме һәм Сабантуй уздырылачак. Бәйрәм чараларында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның катнашуы көтелә.

Яңа оешма булдырыла

Татарстанда бушлай юридик ярдәм күрсәтү буенча дәүләт бюросы оештырыла. Яңа оешма үзләрен яклау өчен адвокатлар яллый алмаган аз керемле, социаль яктан аз якланулы кешеләргә хезмәт күрсәтәчәк. Юстиция министры Рөстәм Заһидуллин әйтүенчә, махсус дәүләт бюросын оештыру карарын Президент Рөстәм Миңнеханов кабул иткән. Хәзерге вакытта Юстиция министрлыгы оешманың эш концепциясен булдыра. Министр фикеренчә, бюро көзен эшләп китәчәк. Анда республикада яшәүчеләр үзләрен борчыган сораулар белән мөрәҗәгать итә алачак.

Үлем очраклары теркәлми

Татарстанда коронавирус белән авыручылар саны кими. Узган тәүлектә республикада авыруның 114 яңа очрагы теркәлде (пәнҗешәмбе – 116). Бу хакта инфекциягә каршы көрәш буенча оператив штаб хәбәр итә.

Тәүлек эчендә 75 кеше хастаханәгә озатылган. Бу алдагы көн белән чагыштырганда 11 процентка күбрәк. Бер атнадан артык республикада әлеге чирдән үлүчеләр юк.

Гомумән алганда, республикада пандемия башыннан бирле чир йоктыручыларның саны 150426га җиткән.

Сүз уңаеннан, Татарстанда әлегәчә битлек кию режимы гамәлдә кала.

Яшьләр дөньясы

ФАЙДАЛЫ ЯЛ
БАЛАЛАР ЭШЛӘП АШАРГА ӨЙРӘНӘ

Уку беткәч... уйнарга ярамый. Мәктәп яшендәге балаларның күпчелеге җәйге ялын эшләп үткәрмәкче. «SuperJob» хезмәте оештырган сораштыру нәтиҗәләре шул хакта сөйли.

Белгечләр Россиядә яшәүче 14–17 яшьлек балалар тәрбияләүче ата-аналардан ул-кызларының җәйге ялын ничек уздырырга җыенуларын белешкән. Ата-аналарның 15 проценты балаларының җәй айларында акча эшләргә теләүләрен әйткән.

Гомумән, 2022 елның май аенда Россия күләмендә үсмерләр өчен 800ләп вакансия тәкъдим ителгән. 2021 елның шул чоры белән чагыштырганда ике тапкыр күбрәк бу.

Күп очракта үсмерләр курьер, промоутер (товар тәкъдим итүче), кафе-рестораннарда официант, теге яисә бу һөнәр иясенең ярдәмче-ассистенты булып урнашу ягын карый. Моннан тыш сатучы, волонтер, консультант, флорист, аниматор кебек хезмәткә урнашучылар да байтак. Эш тәкъдим итә торган сайтларга ышансаң, әлеге вазыйфаларны тырышып башкарган хезмәткәргә 19–60 мең сумга кадәр акча түләргә әзерләр.

Яшүсмерләр эшкә урнашканда һәм аларны эшкә алганда нинди таләпләр үтәлергә тиеш соң? Мәгълүм булганча, 14–16 яшьлек балалар ата-анасы (опекун) ризалыгы белән генә эшкә урнаша ала. 16 яшьтән соң бу карарны мөстәкыйль кабул итәргә мөмкин. Әмма кайбер нечкәлекләрен исәпкә алып кына. Әйтик, эш вакыты атнасына 35 сәгатьтән арта алмый. Үсмер хезмәте һич кенә дә зыянлы, авыр шартларда башкарылырга һәм аңа бәйле булырга тиеш түгел. Һөнәрнең рухи халәткә дә начар йогынты ясарлык булмавы мөһим. Шуңа да балаларны төнге клуб, бар ише җирләрдән ераграк тоталар.

Татарстандагы вазгыятькә килгәндә, 700ләп үсмернең җәен эшләп уздырачагы билгеле инде. Бу хакта республиканың хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова белдерде. Бу яктан Алабуга районы актив икән. Моннан тыш балаларга эш табу белән махсус хезмәт отрядлары, мәшгульлек үзәкләре дә ярдәм итә.

– Күп очракта бик үк имин булмаган, күпбалалы гаиләләрдәге үсмерләр эшкә урнаша. Ягъни өстәмә акчага ихтыяҗ кичергәннәр. Бала өчен кесә акчасы һәрвакытта да эшкә урнашу өчен стимул булып торды, – ди министр.

«HeadHunter» хезмәте юристы, хезмәт хокукы буенча белгеч Татьяна Нечаева, яшүсмерләрнең беренче эше һәм беренче хезмәт хакы сөенеч кенә китерсен өчен кайбер киңәшләрне истә тотарга тәкъдим итә:

• Яшүсмерне эшкә урнаштырганда, иң беренче эш итеп, килешү төзү турында кайгыртырга кирәк. Бу сораугa бик җитди карарга киңәш ителә. Ник дигәндә, һәр бишенче эш бирүче яшүсмер-хезмәткәргә башкарган эше өчен тиешле акчасын түләми икән. Моннан тыш, эш вакытында ул-бу була калса, килешүдән башка матди компенсациягә ирешү кыен булачак.
• Үсмерләрне өстәмә эшкә чакырырга, ял һәм бәйрәм көннәрендә эшкә чыгарырга рөхсәт ителми. Эш сәгате төнге сәгатьләргә туры килергә тиеш түгел (22.00дән 6.00гә кадәр).
• Монысы исә ата-аналар колагына. Закон буенча, яшүсмер эшләгән акчасын үзе теләгәнчә тотарга һәм аларны бераүгә дә бирмәскә хокуклы. Хәтта әнисенә дә (Россия Гражданнар кодексының 26 нчы маддәсе).

Сүзгә-сүз

kremlin.ru

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:

Бүген юл төзелеше тармагындагы иң зур проект булып Европа – Көнбатыш Кытай коридоры кысасында Казахстанга чыгучы М12 Мәскәү – Казан трассасын төзү тора. Алдан килешкәнчә, көнчыгышта әлеге юл Екатеринбург, Төмән һәм Чиләбегә кадәр озайтылачак.

ЯШЬЛӘР ӨЧЕН ИҢ УҢАЙЛЫ ШӘҺӘР

«Работа.ру» хезмәте яшьләр тормышы өчен иң уңайлы саналган Россия шәһәрләрен барлаган. Калаларны сайлаганда, яшьләр өчен кирәкле инфраструктура, белем алу, һөнәри үсеш мөмкинлекләре, күңел ачу һәм хезмәт хакы дәрәҗәсе исәпкә алынган.



1 – МӘСКӘҮ.................. 70%
2 – САНКТ-ПЕТЕРБУРГ.................. 65%
3 – КАЗАН.................. 32%
4 – ЕКАТЕРИНБУРГ.................. 26%
5 – СОЧИ.................. 24%

Яшелчә арзаная, чәй кыйммәтләнә

Май ахырында Татарстанда кайбер ризык бәяләре кимегән. Аерым алганда, яшелчә арзанайган. Татарстанстат мәгълүматларына караганда, 20–27 май аралыгында кыяр хакы 13,95 процентка төшеп, килосы 104,85 сумга калган. Помидор 9,76 процентка арзанайган (килосы – 162,47 сум). Моннан тыш шушы атна эчендә кәбестә – 6,24 процентка (хәзер – 62,51 сум), йомырка – 1,86 процентка (67,98 сум), пешерелгән колбаса – 1,35 процентка (394,29 сум), башлы суган – 1,23 процентка (53,44 сум), шикәр комы 0,88 процентка (83,12 сум) төшкән. Шул ук вакытта арыш, арыш-бодай икмәкләре 0,6 процентка очсызланып, 59,61 сумга калган. Үсемлек мае, сөт, каймак, токмач, кишер һәм банан бәясе дә бераз кимегән.

Ә менә бәрәңге, тоз, чәй, ярымысланган колбаса, балалар өчен ит консервлары һәм маргарин бәясе арткан. Атланмай хакы үзгәрешсез калган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Байлык күп, бәрәкәте юк

Махсус операция башланып, Россия Үзәк банкының ярты резервы, олигархларның капиталы чит илләрдә бикләнгәч, без шуны аңладык: гаҗәп бай илдә яшәгәнбез, әмма мал читкә агылган һәм гади халык өчен дә, хәтта аны ярым рәсми, ярым урлап чит илгә ташыган олигархлар өчен дә аннан хәзер файда юк.

Әйтик, менә миллиардер Авенның Британ банкларында яшерелгән зур байлыклары бар, барлык активларының күләме 4,5 миллиард фунт стерлингка (5,67 миллиард доллар) җитә иде. Санкцияләр китереп кыскач, ул яшәргә акча җитмәвен, машина йөртә белмәвен, ә шофер ялларга акчасы юклыгын әйтеп зар елады. Михаил Фридманның активлары тагын да зуррак – 10,8 миллиард фунтка җитә. Ул да фәкыйрьлектән зарланып, күз яше түгә. Аны Лондон үзәгендәге кыйммәтле итальян ресторанында күргәч, ризык өчен 30 яшьлек табындаш хатын-кыз түләве турында нәтиҗә ясады Россия матбугаты. Юк, мин сары матбугаттан да, тыелган ресурслардан да алмыйм бу мәгълүматны. Россиянең төп пропаганда каналларыннан файдаланам. Фридман хәзер айга 2,5 мең фунт стерлингка гына (200 мең сумга аз гына тулып җитми) яши. Бу язманы укыган һәркем айлык кереме шуның кадәр булса, өстенә бәрәкәт яңгыры яуды дип уйлар иде, тик Фридманның ашы өчен сөяркәләре түли.

Россия олигархларына миллиардларның каян килүе сер түгел. The Economist 2016 елда ук Россиягә «куштанлык икътисады» рейтингында беренче урынны биргән иде. Ул рейтингта Украина да лидерлар арасында. Куштанлык икътисадын икенче төрле «блатлы капитализм» дип тә йөртәләр. Зур чиновниклар белән әшнәлегең булмаса, миллиардлар эшли алмыйсың дигәнне аңлата.

Малның бәрәкәте китсә, миллиардларың булса да, хәтта аларга арест салынмаса да, ачтан үлә аласың. Ташып торган байлыкның кинәт кенә кул астыннан шуып чыгуы бер Россия олигархлары өчен генә хас түгел. Согуд принцларының ничек яшәгәнен беләбез бит инде. Байлык эчендә йөзеп, шәхес буларак таркалып, деградацияләнеп бетте күбесе. Җиңел килгән мал (бигрәк тә бик үк дөрес булмаган юл белән керсә кесәгә) яхшыга илтми, сине җиңел генә ташлап та китә ала. Урының төрмә сәндрәсендә булуы да бик ихтимал. Бу тормыш Тукайның «баскыч»ы кебек: бүген югарыда син, иртәгә кемдер килеп баскычның астын өскә алыштырып та куя ала. Согуд тәхет варисы Мөхәммәд ибн Сәлман, дилбегәне кулга алгач, кыланып та күрсәтте. Башта ул миллиардерларны затлы кунакханәдәге «почетлы төрмә»гә ябып, байлыкларны бюджет белән бүлешергә мәҗбүр итте. «Почетлы» дигәч тә, яшәү урыны абруйлы урында булса да, олигархларга ярыйсы гына тән газаплары да кичерергә туры килүе хакында имеш-мимешләр дә таралды ул чакта. Малдан аерылу тән һәм җан газабыннан башка гына бик мөмкин дә түгел ул. Соңгы көннәрдә Согуд принцлары, фәкыйрьлек чигенә барып төшеп, чит илдәге күчемсез милекләрен, яхталарын һәм картиналарын сатуга куйды. Тәхет варисы, күрәсең, Россия олигархларының милке бикләнүеннән гыйбрәт алгандыр. Принцларны өстенлекләрдән мәхрүм итте, бушлай юл йөрүләрен туктатты, энергетика һәм күчемсез милек өлкәсендәге дәүләт структуралары белән табышлы килешүләр төзүне гамәлдән чыгарды, хәтта хезмәтчеләргә салым кертте. Нәтиҗәсен күрәбез инде: бөлгән шаһзадәләр югалтуларын милекләрен сатып каплый.

Бәрәкәте булмаса, зур акчаның да, сандык-сандык алтын-көмешнең дә, миллиардлаган долларлык облигация-акцияләрнең дә файдасыз булуын дәлилли югарыда сөйләнгәннәр. Шушы урында туктап сорау куыйк: нәрсә соң ул бәрәкәт? Бәрәкәт малның бетмәвен аңлата. Аны синнән беркем дә тартып ала алмый. Күплеге мәҗбүри түгел, аз булса да җитә. Тотасың-тотасың, ә акчаң бетми бер дә. Чыгымнарың керемнәрне күптән узып китте шикелле тоела, акча янчыгы барыбер тулы. Башка: «Әллә минем акча үрчи инде», – дигән уйлар килә. Бәрәкәтнең тагын бер сыйфаты бар: мал җан тынычлыгы белән тотыла. Бетә дип борчылмыйсың, шөкер итеп яшисең, иртәгесе көнгә ышаныч бетми бер дә. Тагын бер нәрсәне истә тотыйк: аз гына кыекка кердеңме, бәрәкәт бетә. Малың белән мактануны яратмый, шулай ук сине ташлап китә. Авыр хәлдәгеләр белән бүлешүне сөя, бүлешкән саен арта.

Хәзер үзебезнең чынбарлыкка әйләнеп кайтыйк. Россия – дөньядагы иң бай ил. Табигый байлыклары буенча рейтингта ул – беренче урында. 75 триллион долларлык табигый байлыклары бар дип исәпләнә. Икенче урында – АКШ. Аның ресурслары – 45 триллион долларлык. Алардан соң Согуд Гарәбстаны, Канада, Иран, Кытай, Бразилия, Австралия, Гыйрак, Венесуэла килә. Беренче унлыктагы Венесуэлада халык ачлыктан интегә. Аның 14,3 триллион долларлык табигый байлыклары бар. Иң байлар сафына кергән илләрнең барысы да глобаль кризис алдында калтырап торалар. Бер-берсен планетакүләм ачлык белән куркыталар. Күбесенең элиталары теген-ди-мондый хәл була калса дип, запас аэродромнар әзерли. Санкцияләр чолганышында калып, кая барып бәрелергә белмәүчеләр байтак. Фонд базары ишелү куркынычы миллиардерларны калтырап торырга мәҗбүр итә. Планетада газ кризисы бара. Шул ук вакытта Төркиянең идарәче партиясе вәкиле Кара диңгездәге табигый газ запаслары гына да бөтен дөньяга 45 елга җитәрлек дип игълан итә. Планетаның кайсы гына почмагына барып аягыбызны җиргә тидерсәк тә, шик юк: табаныбыз җир астындагы гигант байлыклар өстеннән атлый. Әгәр дә түбәндәге барлык алтынны югарыга күтәреп булса, тездән алтынга батып йөрер идек.

Хәзерге көндә халкы ачлыктан интегүче Әфганстан бар. Болар киләчәккә бик зур өмет белән карыйлар. «Әфган литие Согуд нефтенә караганда кыйммәтлерәк», – дип белдерәләр. Яңа әфган идарәчеләре Санкт-Петербургтагы икътисади форумга килергә җыена. Ул илнең Тау-руда һәм нефть сәнәгате министрлыгы яңа гына Амудәрья яры буенда алтын юдыруга тендер игълан итте. Чагыштырыйк: Polymetal – Россиянең икенче урындагы алтын җитештерүче компаниясе Красноярск краендагы яңа проектын ел-ел ярымга туктатып торачагын әйтте. Тагын бер нәрсә бар: Россия алтын приискалары бүген дефолт алды хәлендә. Әфганлылар, әгәр дә гаделлек белән эш йөртә алсалар, аларга бәрәкәт ишекләре ачылачак. Юк икән, алар да бөләчәк. Безне исә бәрәкәт дигәнең бик озакка ташлап китте кебек. Бер безне генә түгел. «Дөнья икътисады 1970 нче еллардан соңгы иң куәтле товар шогы эпохасына кереп бара», – дип белдерә халыкара белгечләр.

ТАТАРСТАН ӨЧЕН КАДЕРЛЕ

tatarstan.ru

Татарстан Президенты – Алтайда. Эш сәфәре кысасында ул биредә «Кар барсы» биологик төрлелекне саклау үзәген булдыру буенча киңәшмә уздырды. Республика җитәкчесе әлеге хайваннарның Татарстан өчен дә әһәмиятле булуын искәртте.

– Шулай килеп чыкты, кар барсы – безнең гербта барлыкка килгән символ гына түгел. Ул Алтай тарихына бәйле. Безнең бурыч исә – кар барсын саклап калу, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Очрашуда Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков төп доклад белән чыгыш ясады һәм булачак үзәкнең үзенчәлекләре турында сөйләде. Үзәк концепциясен Россия Фәннәр академиясенең Северцов исемендәге Экология һәм эволюция проблемалары институтының әйдәп баручы фәнни белгечләре һәм Россия Фәннәр академиясенең Себер федераль агробиотехнологияләр фәнни үзәге әзерләгән.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, үзәкнең кайда урнашачагы турында озак баш ватканнар. Алтайның табигый үзенчәлекләре, җирлекнең ничек урнашуы өйрәнелгәч, республика башлыгы Олег Хорохординның ризалыгын алгач, Алтайда тукталганнар.

Сүз уңаеннан, Алтай барсларның тереклек итү урыны булып тора. Хайваннарга табигатькә ияләшергә туры килмәячәк, алар кирәкле азык базасы булган мохиттә яшәячәк.

Рөстәм Миңнеханов популяцияне торгызырга җыенган мәйданчык белән танышкан инде. Фәнни үзәк зур булмаячак, дип искәртте Татарстан Президенты. Төп территория кыргый, табигый булачак.

– Барстан башлыйбыз, аннан исә Кызыл китапка кергән башка хайваннарга да чират җитәр. Бу – манул, аргали. Фәнни үзәк, вольердан башларга кирәк, – диде ул.

Үзәк территориясе итеп «Карым» хуҗалыгы сайланган. Ул Майминск районында урнашкан. Мәйданы – 9486 га.

Рөстәм Миңнеханов бу зонаның сакланырга тиешлегенә басым ясады. Туристлар, аучылар йөрергә тиеш түгел. «Бу закон белән беркетелгән булсын», – диде ул.

РУС ШИГЪРИЯТЕ КОЯШЫ

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. МИҢНЕХАНОВның Рус теле көнен һәм А.С. Пушкинның тууына 223 ел тулуны бәйрәм итү уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле татарстанлылар!

Сезне ямьле бәйрәм – Рус теле көне һәм «рус шигърияте кояшы» А.С. Пушкинның тууына 223 ел тулу уңаеннан чын йөрәктән тәбрик итәм.

Даһи шагыйрь бөек иҗатыннан үзенә һәйкәл кую, күпсанлы әдәбият сөючеләрнең күңелен мәңгелеккә яулау белән беррәттән, рус теленең энҗе-гәүһәрләргә тиң сүзләрен камиллек тәхетенә күтәрде, әдәбиятка хөрлек, ихласлык һәм чын халыкчанлык рухын алып килде. Рус шигърияте, күпмилләтле Россия һәм гаять киң рус дөньясы өчен Пушкин бәяләп бетергесез биеклектәге, Сергей Есенин сүзләре белән әйткәндә, рус халкының язмышына әйләнгән шәхес. Пушкинның үлемсез шигърияте һәм һәркемгә яхшы таныш образы рус әдәбияты, Россиянең күпкырлы мәдәнияте белән бик тыгыз рухи бәйләнештә, шуңа да халыкара Рус теле көне хаклы төстә мәшһүр шагыйрьнең туган көнендә билгеләп үтелә.

Россия Федерациясендә генә түгел, элеккеге Советлар Союзына кергән күпчелек илләрдә дә халыкларның үзара аралашу чарасы булган рус теле – бүген дә дөньядагы иң зур әһәмияткә ия булган телләрнең берсе. Бик күп гасырлар дәвамында төрле халыклар дус-тату, бер-берсен хөрмәт итеп яшәгән Татарстанда, татар һәм башка милләтләр телләре белән беррәттән, рус телен үстерүгә һәрвакыттагыча зур игътибар бирелә. Илебез этник берлекләренең үзенчәлекләрен, милли-мәдәни төрлелеген саклауны максат итеп куйган Россия халыкларының мәдәни мирасы елында гомум тел байлыгыбызны танытуга юнәлдерелгән эшчәнлекне киңрәк җәелдерү аеруча мөһим.

Соңгы вакытларда кайбер чит илләрдә рус мәдәниятен тыю омтылышы күзәтелә. Мондый шаукымга карата күренекле совет шагыйре Ярослав Смеляковның сүзләрен китерү урынлы булыр: «Рус теленең асылына ялгыш кына кагылганнар – хакимнәр дә хәтта шул мизгелдә бөтенләйгә юк булганнар». Вакытлар узу белән тарих барысын да гадел хөкем итәр, бөек рус мәдәнияте Европа мәйданында һәм бөтен дөньяда элеккечә үзенә лаеклы урын биләр дип ышанам.

Кадерле дуслар, сезгә тынычлык, бәхет һәм иминлек, Рус теле көнен Пушкин иҗатыннан, якын дусларыгыз һәм фикердәшләрегез белән аралашудан хозурланып, файдалы һәм күңелле итеп уздыруыгызны телим.

Дуслык утравы

Татарстан Халыклар дуслыгы йортында Халыклар ассамблеясына 30 ел тулуга багышланган фотокүргәзмә ачылды. Дәүләт Советы Рәисе, Халыклар ассамблеясы советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин күргәзмә белән танышты.

«Без Татарстанда яшәвебезгә шатбыз һәм милләтара тынычлык-татулык мәсьәләләрен дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә күтәргән өчен республика җитәкчелегенә рәхмәтлебез», – диде Халыклар ассамблеясы башкарма советы җитәкчесе Константин Яковлев. Ул Ассамблея Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинга һәр милли-мәдәни автономия тормышында актив катнашуы өчен рәхмәт белдерде. Ассамблеяның башкарма советы җитәкчесе, 75 яшьлек юбилее һәм Ассамблея советы Рәисе вазыйфасында эшләвенә 15 ел тулу уңаеннан котлап, Фәрит Мөхәммәтшинга «Халыклар бердәмлеген саклау һәм ныгыту өчен» истәлек билгесен тапшырды.

Дәүләт Советы Рәисе, үз чиратында, Татарстан Халыклар ассамблеясының республикада милләтара тотрыклылыкны һәм тынычлыкны саклауга зур өлеш кертеп килүен искәртте. «173 милләт вәкилен үзенә сыендырган республикабыз уңышларын милләтара тынычлык-татулыктан башка күз алдына да китереп булмый. Бу – күпмилләтле республикабызның иң зур байлыгы», – диде ул.

ҮЗЕҢ ТӨЗЕГӘН ОТЫШЛЫРАК

Россия Хөкүмәте моңа кадәр булмаган программа башлап җибәрде. Аның асылы профессиональ төзүчеләр белән килешү төземичә генә үз көчең белән йорт салучыларга ташламалы кредитлар тәкъдим итүдән гыйбарәт. Бу турыдагы карарга Россия Премьер-министры Михаил Мишустин кул куйган.

ДОМ.РФ генераль директоры Виталий Мутко сүзләренчә, ипотека ставкасы 9 процентны тәшкил итә. Тагын берничә процентны банкларга дәүләт компенсацияли. Сүз уңаеннан, әлеге программада 70ләп банк катнаша алуы билгеле. Ипотеканы быелның 1 июленнән бирергә уйлыйлар. Быел пилот проект өчен Россия буенча 8 мең кредит бирергә исәплиләр. Мәскәү, Санкт-Петербург, Мәскәү һәм Ленинград өлкәләрендә субсидияләнгән ставка буенча бирелә торган займның максималь күләме 12 млн сум булса, калган төбәкләргә 6 млн сум каралган.

Дөрес, әлегә программаның шартлары һәм нечкәлекләре билгеле түгел. Әйтик, йорт салырга ниятләгән кешенең кулында ничә сум акчасы булырга тиешлеге, җир кишәрлегенең мәйданы, залог буларак нинди милекне тәкъдим итәргә мөмкин булуы – әлегә берсе дә мәгълүм түгел.

Шул ук вакытта төзелеш тирәсендә кайнашкан кешеләр Россия һәм Татарстан өчен 8 мең кредитның бик аз булуын әйтте. Мәсәлән, Татарстан буенча Росреестр мәгълүматлары буенча, быелның апрелендә – 6,3 мең, мартта – 9,5 мең, февральдә 7,6 мең килешү төзелгән. Әле бу милек базарында иң авыр елларның берсе булып санала. Билгеле, төзелеш гөрләп барган елларда саннар бермә-бер арта.

Риэлтор Айгөл Җәләева фикеренчә, әлегә бу программа ике төрле уйларга урын калдыра.

– Сүз дә юк, әлеге программа үз йортлары белән яшәргә теләүчеләр өчен отышлы. Ләкин бүгенгә җаваптан бигрәк, сораулар күбрәк. Кешеләр үз участокларында төзиячәк, ә залогка нәрсә булачак? Һәм монда тагын бер сорау кала: әгәр банк кешегә акча бирсә, алар чыннан да йорт салуга тотылырмы, аны ничек дәлилләргә? Тиздән бу сорауларга ачык җаваплар булыр дип уйлыйм. Моннан тыш, минем фикеремчә, ташламалы ипотека турында сүз барганда, 9 процент аз түгел. Ул 5–6 процент булырга тиеш, – диде Айгөл Җәләева.

Шулай да, белгечләр фикеренчә, әлеге программада катнашырга теләк белдерүчеләр күп булачак. «ДОМ. РФ» һәм Бөтенроссия җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге уздырган тикшерену нәтиҗәләре нәкъ шуны күрсәткән. Баксаң, ипотека алып, үз йортларын салырга җыенучыларның 31 проценты бу эшкә профессиональ төзүчеләрне җәлеп итмичә, үз көчләре белән генә башкарып чыгарга ниятли. Моннан тыш, узган ел Россиядә төзелгән йортларның яртысыннан күбрәге халыкның үз көче белән сафка баскан. Соңгы тапкыр мондый күренеш узган гасырның кырыгынчы елларында булган. Быелның алты аенда төзелгән йортларның 62 процентын да кешеләр үзләре салып чыккан. Сораштыру нәтиҗәләре россиялеләрнең 73 процентының үз йортлары белән яшәргә теләвен күрсәткән.

– Бу яктан караганда яңа чаралар ипотека алырга зуррак мөмкинлекләр бирәчәк, – дип саный «Дом.РФ»ның идарәче директоры Светлана Некрасова. – Әлеге ташламалы ипотека ярдәмендә Россиядә якынча тагын 1 млн кв. метр торак сафка басар дип уйлыйбыз.

Зөһрә САДЫЙКОВА

САБЫЙЛАРГА ҖӘЛ ТҮГЕЛ

Яшәеш

Татарстанда 791 балага яман шеш диагнозы куелган. Алар Республика клиник балалар хастаханәсендә исәптә тора. Узган ел исә 129 сабыйда мәкерле авыру барлыгы ачыкланган. Чир яшенә, җенесенә карап тормый. Әле бер яше дә тулмаган сабыйларда да яман шеш барлыгын ачыклыйлар икән. Бу хакта Татарстан Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетының күчмә утырышында сөйләштеләр.

«Татар-информ»

Иң элек депутатлар Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургиясе үзәгенең эшчәнлеге белән таныштлар. Республика балалар клиник хастаханәсенең баш табибы Айрат Зиатдинов сүзләренчә, бу үзәкнең ачылуына бер генә ел булса да, биредә 2 меңнән артык яшь пациент тикшерену узган. Хәзерге көндә 100 бала дәвалана. Бирегә башка төбәкләрдән дә киләләр.

– Әлеге үзәк «Сәламәтлек саклау» илкүләм һәм «Татарстанда балалар сәламәтлеге үсеше» төбәк проектлары кысасында төзелде. Үзәктә кан салу бүлеге эшли. Сөяк җелеге күзәнәкләре донорлары реестры алып барыла. Киләчәктә сабыйларга сөяк җелеге күзәнәкләрен дә күчереп утыртa башлаячакбыз. Әлегә бу катлаулы операцияне Мәскәү һәм Санкт-Петербургта гына ясыйлар иде, – ди баш табиб. – Гемопоэтик күзәнәкләрне бу елның икенче яртысында күчереп утыртa башларбыз дип торабыз. Пациентлар инде сайланды, алар операциягә әзерләнә. Табиблар да әзерлек узды. Әлегә алар әйдәп баручы федераль клиникаларда тәҗрибәләрен ныгыталар. Андый пациентлар өчен үз микроклиматы белән блок тибындагы махсус җиде палата әзерләнеп куелды.

Татарстан Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты рәисе Светлана Захарова сүзләренчә, әлеге үзәкне төзү җиңел генә булмаган.

– Бу үзәк бүген онкология авыруларына югары квалификацияле диагностика һәм дәвалау курсы үткәрә. Без бирегә килгәч, эшнең ничек оештырылуын гына түгел, нәрсәгә игътибар итәргә кирәклеген дә өйрәнәбез. Безгә мөрәҗәгатьләр күп килә. Авыручылар даруларның кыйммәтләнүенә борчыла. Санкцияләр аркасында дәвалануны дәвам итеп булырмы дип сорыйлар, – ди Светлана Захарова.

Комитет рәисенең соравына Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Фәридә Яркәева шунда ук җавабын да бирде. Баксаң, борчылырлык урын юк икән. Элеккеге дару кайтаручылар араны өзмәгән. Бәяләренә килгәндә, аларны да контрольдә тоталар. Тиешеннән күбрәк бәягә сатучыларга җәза да бирелә икән. Тагын шунысы бар: санкцияләр аркасында даруларны кайтарту бәясе арткан. Әмма ни генә булмасын, табиблар яман шеш авырулы балаларның әниләрен тынычландырырга тырыша. Алар, сабыйларның гомерен саклап калыр өчен барысын да эшлибез, ди.

Хастаханәдәге заманча җиһазларның булуы чирне вакытында ачыкларга ярдәм итә икән. Республика балалар клиник хастаханәсенең онкология бүлеге мөдире Лия Кәримова әнә шулай ди.

– Элегрәк без сабыйлардагы яман шешне 4 нче стадиядә генә ачыклый идек. Ә хәзер бар да башкача. Әти-әниләр дә сизгер, участок табиблары, онкологлар да тиз арада безгә җибәрү ягын карый. Үзегез беләсез: вакытында ачыкланган авыруны дәвалап та була. Яман шеш белән очрашкан балаларның 75 процентын коткарабыз. Медицина алга бара, соңгы биш елда яман шеш диагнозы ачыклангач, балаларның беренче елда ук вафат булу күрсәткече дә кими, – ди ул.

Үзәкне карап чыккач, күңелгә авыр да булып китте. Бер уйласаң, дәваланыр өчен мөмкинлекләр җитәрлек. Ә нигә соң алайса, сабыйларны чит ил клиникаларында дәвалар өчен дип, тиенләп акча җыябыз. Бу сорауны баш табиб урынбасары Альмира Мостафаевага да бирдек. Аның фикеренчә, илдәге бар табиб та бер төрле схема белән эшли. Безнекеләр дә чит илнекеләрдән ким түгел икән.

– Әти-әниләр нигәдер чит илгә барып дәвалануны сайлый. Әмма бүгенге мөмкинлекләр белән үзебездә дәвалап була. Безнең табиблар федераль үзәктәгеләр белән элемтәдә тора. Сабыйларны Мәскәүгә, Санкт-Петербургка җибәрәбез. Соңгы елларда Россиядә дәваланып аякка баскан сабыйлар шактый, – ди ул.

Әниләрне аңлап була. Аларның да кая барып бәрелергә белмәгән чаклары күп. Табиблар да авыр чакта дога кирәген аңлый. Шушы көннәрдә яңа үзәктә мөселманнар өчен гыйбадәтханә бүлмәсе дә эшли башлаган.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КИЛӘСЕ ЯЗГА ӨМЕТ

Спорт кына түгел бу

«Рубин»га бәхетсезлек алып килгән язның соңгы көнендә Казан клубы берьюлы биш яңа уенчы белән килешү төзеде. Исемнәре футбол белән искә төшкәндә генә кызыксынучы тамашачы өчен таныш түгел. Казанда яңа команда коралар. Алда нинди бурыч торганлыгы хәзердән үк аңлашыла: киләсе язда премьер-лигага әйләнеп кайту.

Берничә көн элек Россиянең футбол берлеге (РФС) футбол клубларының 2021 елгы финанс күрсәткечләрен игълан итте. Анда әйтелгәнчә, узган ел «Рубин» 1,18 миллиард сумлык табыш алган. Бу – премьер-лига клублары арасындагы иң зур күрсәткеч. Әйтик, икенче урындагы «Арсенал»ныкы 135 млн сумны тәшкил итә. Гомумән, табыш алган клублар бармак белән генә санарлык – алар нибары 6. Шулардан бишесенең гомуми табышын бергә кушсаң, әлеге сумма «Рубин»ныкының өчтән бере кадәр генә килеп чыга. Әлбәттә, РФС игълан иткән мәгълүматларда башка саннар да бар. Әйтик, «Рубин»ның кредит буенча әҗәте 2 млрд сумнан артып китә. Әмма 2019 елда әлеге күрсәткеч тагын да күбрәк – 3 млрд сумнан артыграк булган. Бу исә соңгы елларда Казан клубында акча мәсьәләсенең җайга салынуын раслый.

Акча димәктән, «Рубин»ның генераль директоры Рөстәм Сайманов журналистлар белән очрашкач, бу мәсьәләне дә читләтеп узмады. Казан клубында өстәмә миллионнарны чит илдән очсызгарак бәягә уенчы алып, соңрак аларны кыйммәткәрәк сату ярдәмендә эшләргә җыенганнар. Россиядәге футболчыларга мондый алым туры килми. Чөнки безнекеләр өчен, алар әле тупка тибәргә өйрәнер-өйрәнмәс борын, берничә тапкыр күбрәк акча сорыйлар. Тик «Рубин»ның хыялларын Европаның футбол түрәләре пыран-заран китерде. Мәгълүм вакыйгалар башлангач, алар Россиядәге чит ил уенчыларына рөхсәтсез-нисез үзләренә кайтып китәргә рөхсәт бирде. Казандагы 6 уенчы шулай итте дә. Хезмәт хакы, тыныч тормыш вәгъдә ителсә дә, төенчекләрен төйнәп юлга кузгалганнар. Барысы да – төп футболчылар. Нәтиҗәдә «Рубин»га сезонның хәлиткеч өлешен кул астында кем бар, шулар белән тәмамларга туры килде. Ахыры ничек беткәне билгеле. Ул гына да түгел, хәзер, гомумән, чит ил уенчыларының Казанга кире кайтачагы да икеле инде. Беренчедән, Европада Россия футболына карата хәерхаһлы карар чыгарасылары шикле. Аларга килешүгә төкереп, кая телиләр, шунда уйнарга рөхсәт бирәселәрен чамаларга мөмкин. Икенчедән, чит ил уенчылары ФНЛда чыгыш ясарга теләр микән? Шулай итеп, футболчы да, аларны һич югы сату мөмкинлеге дә юк. Әйтик, хорват сакчысы Филип Уремович Алманиянең «Герта» клубы белән килешү төзеде. Аның яңа клубы безнекеләргә бер тиен дә түләмәячәк. Узган ел исә алманнар 4 млн евро түләргә риза иде.

Офыкта әнә шундый авыр вазгыять шәйләнә башлагач, «Рубин» да өметле күзләр белән Мәскәү ягына төбәлде. Премьер-лига командаларының санын 18гә арттырып булмасмы, янәсе. Алайса, футболчылар качыша, уенның җае китә, гаделсезлек барлыкка килә. Бу хакта сөйләшүләр әле март ахырында ук башланды. Рөстәм Сайманов әйтүенчә, «Рубин»ның бу вакыйгалардан иң зур зыян күргән клуб булганын барысы да таныган. Дөрес булса, Мәскәүдә ул чакта бу тәкъдимне кабул иткәннәр, хәтта вәгъдә дә биргәннәр. Ә премьер-лига уеннары тәмамланып өч көн үткәч, Россия футбол берлегенең башкарма комитеты утырышында хәлиткеч карар чыгардылар: командалар саны үзгәрми. Кем әйтмешли, суга батучыларны коткару – суга батучыларның үз эше.

Шулай итеп, ике тапкыр чемпионлык шатлыгын кичергән, Европаны шаулаткан «Рубин»га иң көчлеләр арасында уйнарга лаек икәнен кабаттан расларга туры киләчәк. «ФНЛда калсак, бу җинаятькә тиң булачак», – ди Рөстәм Сайманов. Бер елдан иң көчлеләр сафына әйләнеп кайтырга телиләр. Әмма җиңел булмаячак. Бер үк туп белән уйнасалар да, премьер-лига белән ФНЛ арасындагы аерма аз түгел. Шул ук Сайманов сүзләре белән әйткәндә, РПЛда рәссамнар чыгыш ясый, ягъни иҗатка урын бар, ә ФНЛда күбрәк көрәшергә туры килә. Казан командасының яңа составын да әнә шуңа карап туплыйлар. Язның соңгы көнендә «Рубин» берьюлы 5 яңа футболчы белән килешү төзеде. «Енисей»дан Александр Зотовны, «Кубань»нан Валерий Чуперканы, «Балтика»дан Артем Поповны, безнекеләргә премьер-лигадан төшеп калырга «ярдәм иткән», аннары үзләре дә шул ук язмышка дучар булган «Уфа»дан Олег Иванов белән Дмитрий Кабутовны чакырып китерделәр. Соңрак бу исемлеккә Гана футболчысы Джоэль Фамейе да өстәлде. 25 яшьлек спортчы моңа кадәр «Оренбург»та туп типте һәм команданың иң нәтиҗәле уенчысы булып танылды.

Киләсе сезон яңартылган команда өчен генә түгел, Леонид Слуцкий өчен дә зур сынау булачак. «Рубин» белән килеп чыккан хәлләрдән соң тәнкыйтьнең төп өлеше нәкъ менә баш тренерга эләкте. Кызган баштан әйтелгәне дә, гадел фикерләр дә булды. «Рубин»да калуы исә Слуцкийның җаваплылыгын һәм аның үз ялгышларын төзәтергә теләгәнен раслый. Ә хаталар аз булмады Казан клубында соңгы елларда. «Җиргә төшү» киләчәктә азрак ялгышырга ярдәм итәчәк.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

rubin-kazan.ru

Фикер

Алексей САФОНОВ, футбол агенты:

Беренче лига аша узмаган бер генә клуб та юк. ЦСКА, «Спартак», «Динамо» — барысы да әнә шундый чистарыну аша узды. Була торган хәл, ул кадәр куркыныч түгел. Бу сынау аларны көчлерәк итәчәк. Алга таба ике адым ясар өчен, кайчак бер адым чигенү кирәк. «Рубин» белән дә шулай килеп чыгар дип өметләнәм. Алар бер елдан кабат премьер-лигага әйләнеп кайтырлар дип уйлыйм. Тамашачының да мөнәсәбәте мөһим. Алар команданы ташламас дип өметләнәм.

Тел һәм дин

1100 ел элек Идел Болгарстанында ислам дине кабул ителү уңаеннан газетада тарих фәннәре докторы, профессор Фаяз ХУҖИН ярдәме белән тарихи язмалар циклы тәкъдим ителде. Бүген галим укучыларыбыз сорауларына җавап бирә.

Болгар 922 2022

Соңгы вакытта тарих фәннәре докторы Фаяз Хуҗин үткәнебез турында шактый мәгънәле язмалар биреп барып, бик яхшы эшли. Әмма мин үзем ислам дине тарихына бер яклы гына караш белдерү хакыйкатькә сыешып бетми дип уйлыйм. Нигә әле Ибн Фадлан ислам тәгълиматын урнаштыру, аны ныгыту өчен генә килгән дип исәпләнә? Борынгы Болгар дәүләтен күзәтеп үстерү, чикләрен ныгытуга юнәлеш алу дини фикер белән генә эшләнми бит ул. Бу очракта Багдад хакимлеге, хәзергечә әйтсәк, үзенә союзник эзләмәдеме икән?

Ислам тәгълиматы мәҗбүриләнгәч, дога кылу гарәп телендә мәҗбүри ителгәч, татар теле гарәп, фарсы телләре белән чуарлана түгелме соң? Фаяз Хуҗин шул сорауларга җавап бирсә иде.

Әнис ЗАРИПОВ. Казан

Хөрмәтле Әнис әфәнденең сораулары дөрес куелган. Чыннан да, Багдад кадәр Багдадтан составында дин әһелләре, сәясәтчеләр, оста төзүчеләр һәм мигъмарлар (архитекторлар) булган олы һәм мәртәбәле илчелек Алмыш/Җәгъфәр ибне Габдулла ханның Мөктәдир хәлифәгә юллаган хатында күрсәтелгән үтенечләрне тормышка ашыру өчен генә килмәгәндер, дип уйларга нигез бар. Бу сорауга төплерәк җавап бирү өчен Багдад хәлифәлегенең шул чордагы тормышына, эчке хәленә күз салырга кирәк.

Багдад хәлифәлеге, тарихта «гадел хәлифәләр» («праведные халифы») исеме алган Әбү Бәкер (632–634), Гомәр (634–644), Усман (644–656) һәм Али (656–661) идарә иткәннән соң барлыкка килгән Үмәййә/Омейяд хәлифәлегенең (661–749) дәвамчысы буларак, 750 елда оеша һәм монгол-татар яуларына кадәр яши (750–1258). Икътисад, мәдәният һәм фән үсеше ягыннан караганда урта гасырлар чоры Шәрык дөньясының иң алга киткән дәүләтләреннән санала. Яулап алу сугышлары алып барылмый диярлек, бу исә икътисад үсешенә уңай йогынты ясый. Халыкның күп өлеше сугарулы игенчелек һәм терлекчелек (башлыча дөя асрау) белән шөгыльләнә. Шәһәрләр исә һөнәрчелек һәм сәүдә үзәкләре буларак таныла. Икътисадта тышкы сәүдә зур роль уйнаган. Язма чыганаклар Багдадка ерак Скандинавиядән Идел юлы белән Болгар аша килгән варяг сәүдәгәрләрен телгә алалар.

Хәлифәлектә Багдад, Фустат, Баср, Куфа ише зур шәһәрләр күп була. Аларда яшәүче халыкның саны 100 меңнән алып, 400–500 меңгә кадәр җитә. Шунысын да өстәп әйтик: IX гасырга караган чыганакларда әлеге шәһәрләрдә кирпечтән салынган 5–7, хәтта 14 катлы йортлар булуы турында мәгълүматлар сакланган. Алгарышлы үсеш чоры X гасырга кадәр дәвам итә.

908 елда, хәлифә әл-Мөктафи вафатыннан соң, Багдадта тәхет өчен көрәш башлана. Тәхеткә әл-Мөктафиның 13 яшьлек энесе әл-Мөкътәдирне утырталар. Йомшак характерлы, төрле якның үгетләренә тиз бирешүчән, сәяси тормыштан шактый ерак торган хәлифә 932 елга кадәр идарә итә. Үзе исә күп вакытын хәрәмдәге хатын-кызлар янында кәеф-сафа корып үткәрә, төрле бәйрәмнәр, күңел ачулар оештыра. Дәүләт казнасы бушап кала диярлек. Дәүләт тирән кризис кичерә, Шәрык дөньясында үзенең элеккеге абруен югалта.

Нәкъ менә шул вакытта аның кулына болгар патшасы Алмышның хатын тапшыралар. Аңа һичшиксез уңай җавап бирергә кирәк! Мөкътәдирнең зирәк акыллы, сәясәттә инде шактый тәҗрибәле вәзире эшнең асылын аңлатып бирә: кайдадыр ерак төньякта урнашкан зур гына бер дәүләтне ислам дөньясына җәлеп итү һәм аның йогынтысын якын күршеләренә тарату Багдад хәлифәлегенең халыкара абруен тагын да үстерәчәк. Өстәвенә бит әле Болгарның нык үскән сәүдә иле булуы турындагы хәбәрләр дә бар. Тышкы сәүдә һәрвакыт зур табыш китерә. Димәк, Болгар иле белән тыгыз мөнәсәбәтләр урнаштыру икеләтә файдалы булачак!

...Багдад илчелеге 922 елның 21 май тантаналарыннан соң Болгардан тиз генә китәргә җыенмый әле. Ибн Фадлан һәм аның юлдашлары озак кына – көзгә кадәр! – ил белән танышып йөриләр: бәрәнҗәрләр янында булалар, Идел буенда бай варяг (рус) сәүдәгәрен күмү процессиясендә катнашалар, урманнарга баралар, көн саен халык арасында кайнашалар, сорашалар-белешәләр, күзәтәләр.

Әхмәд ибн-Фадланның илчелек эшчәнлеге турында Багдадка әйләнеп кайткач язылган хисабы – шул күзәтүләрнең, сораштыруларның нәтиҗәсе. Шулай да төп нәтиҗә – Болгар белән Гарәп хәлифәлеге арасында урнашкан сәүдә мөнәсәбәтләре һәм мәдәни бәйләнешләрдыр. Бу фактлар болгар шәһәрләрен казыганда еш табыла торган гарәп дирһәмнәрендә дә чагыла.

Болгар дәүләте Багдадның союздашы булып китә дип әйтә алмыйбыз – бер-берсеннән бик еракта урнашканнар, практик яктан андый союздашлыкның файдасы булмас иде. Болгарның Багдад илчелеге ярдәмендә Ислам цивилизациясенә килеп кушылуы үзе генә дә зур мәртәбә, минемчә. Шул җәһәттән болгарлар тарафыннан элек-электән кулланылып килгән руника нигезендәге язмачылыкның гарәп графикасы белән алмашынуын да мәдәниятебез тарихында уңай күренеш дип әйтеп үтәр идем. Руника – ташка чокып язуга җайлашкан язу, гарәп хәрефләре белән исә кәгазьгә язу уңайлы. Шул графика безгә мең елдан артык хезмәт итте! Әйе, Коръән һәм гарәп язмачылыгы белән телебезгә күп кенә гарәп-фарсы сүзләре дә килеп керде. Телебез чуарланды дип әйтмәс идем. Урта гасырлар чоры гарәп-фарсы поэзиясеннән үтеп кергән матур сүзләр ич алар. Еш кулланылмый торган сүзләр – андыйлары да күп – төшеп кала алар. Ә менә кирәксә дә, кирәкмәсә дә кулланыла торган урыс һәм инглиз сүзләре телебезне нык боза.

Хөрмәт белән, Фаяз Хуҗин.

Теш үтмәслек түгел лә...

БДИ – 2022

Рус теле һәм математика сынаулары артта калды. Билгеле булганча, әлеге имтиханнар аттестат алу өчен кирәк. Берәүләр БДИдан котылырга өлгерсә, икенчеләр белемнәрен күрсәтүне дәвам итә әле. «Үзеңне тыныч тотсаң, тапшырып була», – ди имтиханны үз башыннан кичерүчеләр. Белемне бәяләргә иртәрәк әле, ә тәртипне?

Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин беренче сынауларда кагыйдә бозучылар булмавын әйткән иде. Билгеле, аны тапшыручылар саны кимрәк иде. Башка сынаулардагы вазгыять турында соңрак хәбәр итәрбез.

Күз тимәсен, Татарстанда имтиханнар көйле бара. Воронеж шәһәрендә исә ут сүнү сәбәпле, имтихан нәтиҗәләре исәпкә алынмаячак. Югыйсә рус теле сынавы тәмамланырга ярты сәгать кенә калган булган. Хәзер укучыларга аны кабат тапшырырга туры киләчәк. Бу инде аттестат алу да соңарачак дигән сүз.

Без район укучыларының имтиханнарны ничек тапшыруы турында кызыксындык. Нурлат районында быел 11 нче сыйныфны 179 укучы тәмамлаган. Укучылар саны кими, узган ел аларның саны 204 булган.

Нурлат районының мәгариф идарәсе башлыгы Алсу Рәхмәтуллина белдергәнчә, моңа кадәр сынаулар тыныч кына узган. Бу – тәртип бозуларны алдан кисәтү нәтиҗәсе.

– БДИдан курку хисе бетте дип әйтеп булмый. Әмма быел укучылар үзләрен башкачарак тота. Алар 9 нчы сыйныфтан соң имтихан тапшырмады бит. Бәлкем, шуңа күрәдер. Бөтен нечкәлекләрен белеп бетермиләр. Бар җирдә дә – видеокүзәтү җайланмасы, үз көчегезгә генә таяныгыз дип аңлатабыз, – ди Алсу Рәхмәтуллина.

Быел Нурлатта математикадан профиль сынавын тапшыручылар күп икән. Андыйлар – 91. Информатиканы сайлаучылар да аз түгел. Бу техник вузларга керү теләгенә бәйле. Шулай ук укытучы, төзүче булырга җыенучылар да арткан. Максатчан юнәлеш (целевиклар) буенча 13 кеше медицина вузына барырга теләк белдергән. Узган ел 5 укучы 100 балл туплаган. Араларында Санкт-Петербург, Мәскәү вузларына керүчеләр дә бар.

Беренче сынаулар куркытса да, икенче, өченчеләрендә укучылар үзләрен тыныч тота. Әнә 11 нче сыйныф укучысы Регина Гыйниятуллина соңгы имтиханын тапшырган инде.

– Рус әдәбияты сынавына бик борчылып барган идем. Сораулар катлаулы булмады. Рус теле сынавында алай ук борчылмадым. Анысы да теш үтәрлек. Якынча балларны да чамалыйм. Иң мөһиме – каушамаска кирәк. Тыныч булсаң, эшлисең. Бездә тәртип бозу очраклары булмады, – ди Регина Гыйниятуллина.

Сәрия МИФТАХОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Югары дәрәҗәдә һөнәри осталыгы, коронавирус инфекциясе (COVID-19) эпидемиясе чорында медицина ярдәмен оештыру һәм күрсәтүдәге казанышлары өчен Татарстан Республикасы «Ашыгыч медицина ярдәме» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең бүлек мөдире **Соболев** Андрей Геннадьевич **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Пирогов ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Югары дәрәҗәдә һөнәри осталыгы, коронавирус инфекциясе (COVID-19) эпидемиясе чорында медицина ярдәмен оештыру һәм күрсәтүдәге казанышлары өчен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы урынбасары **Бурмистров** Михаил Владимирович **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Лука Крымский медале** белән бүләкләнде.

* * *

Авыл хуҗалыгы өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Татагрохим» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Гобәйдуллин** Наил Фарук улына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты» федераль дәүләт казна югары белем бирү мәгариф учреждениесенең финанс-икътисад бүлеге башлыгы, полиция полковнигы **Гыйльманов** Рөстәм Камил улына; «ТАНЕКО» акционерлык җәмгыяте нефть эшкәртү заводы нефть продуктларын су белән чистарту һәм элементар күкерт алу производствосының күкертле нефть продуктларын су белән чистарту цехы башлыгы **Илюхин** Константин Викторовичка; «Ак Барс» кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Питрәч җитештерү мәйданчыгы директоры **Кахаберидзе** Вефхвия Владимировичка; Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары ярдәмчесе **Кирпичников** Алексей Константиновичка; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын гамәлгә ашыру бүлеге баш киңәшчесе **Мәннанов** Рөстәм Марат улына; Намуссыз йорт төзүчеләрнең гамәлләреннән зыян күргән затларга ярдәм итү республика фонды башкарма директоры **Новиков** Иван Александровичка; Татарстан Республикасы Актаныш район суды администраторы Муразуллин Айрат Мәгъсүм улына; Казан шәһәре Киров районы прокуроры урынбасары **Фәйзрахманов** Радик Рафис улына; Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Мамадыш шәһәре башлыгы урынбасары **Әгъләмов** Айнур Хәлим улына; Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге башлыгы **Алиев** Эрнест Хәбибулла улына; Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Чырпы авыл җирлеге башлыгы **Евдокимов** Радик Александровичка; Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары **Карсалов** Андрей Геннадьевичка; Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының авыл җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек бүлеге башлыгы **Садриева** Илсөяр Шамил кызына; Чаллы шәһәре Комсомол районы һәм Татарстан Республикасы Тукай районы хәрби комиссары **Вәлиев** Дамир Шамил улына; Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге әйдәүче белгече **Җамалетдинова** Люция Сәгыйть кызына; Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлекчәсе – Татарстан Республикасы буенча Милли банкның икътисад бүлеге башлыгы **Кирсанова** Елена Владиславнага; Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе бүлекчәсе – Татарстан Республикасы буенча Милли банк идарәчесе урынбасары **Хәйруллина** Нурания Фазыл кызына; хезмәт ветераны **Вахитова** Рушания Мостафа кызына; «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционерлык җәмгыятенең «ШАЯН ТВ» башкарма директоры – баш мөхәррире **Сәхәбетдинова** Рамилә Әхмәтзакир кызына; «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Шәһри Казан» газетасы редакциясе» филиалы хәбәрчесе **Шәрәпова** Йолдыз Әдип кызына; «Файдалы казылмалар запаслары буенча дәүләт комиссиясе» федераль бюджет учреждениесенең Казан филиалы директоры (Казан шәһәре) **Гатиятуллин** Нәкыйп Сәлах улына; «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Геология һәм нефть-газ технологияләре институтының А.А. Трофимук исемендәге нефть һәм газ геологиясе кафедрасы мөдире, «Файдалы казылмалар запаслары буенча дәүләт комиссиясе» федераль бюджет учреждениесенең Казан филиалы штаттан тыш эксперты (Казан шәһәре) **Успенский** Борис Вадимовичка; «Файдалы казылмалар запаслары буенча дәүләт комиссиясе» федераль бюджет учреждениесе генераль директоры **Шпуров** Игорь Викторовичка; «Сосна» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Ситдыйков** Фирдәүс Габдулла улына; «Транспорт корылмаларын проектлау институты» акционерлык җәмгыяте генераль директорының проектлау буенча урынбасары **Талипов** Нияз Миңнерәкыйп улына; Татарстан Республикасының «Татарстан китап нәшрияты» дәүләт унитар предприятиесе генераль директорының коммерция мәсьәләләре буенча урынбасары **Хөснетдинов** Илдар Салихҗан улына; Казан (Идел буе) федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институты Чит телләр һәм тәрҗемә югары мәктәбенең халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чит телләр кафедрасы мөдире **Бушканец** Лия Ефимовнага; «Ремсельбурвод» акционерлык җәмгыятенең машина йөртүчесе **Галәүтдинов** Илнур Мансур улына; **«Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте коллективына Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

* * *

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының инвестиция сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге башлыгы **Гафуров** Илдар Шәүкәт улы; авыл хуҗалыгында җитештерүне һәм җир мелиорациясен үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Сарман «Мелиорация» КМК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Хәмматов** Зөлфәт Мирзамөхәмәт улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Финанс-икътисади эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Чаллы «Мелиоводстрой» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш бухгалтеры **Алпарова** Рузидә Хәсән кызы; җитештерүдә югары казанышларга ирешүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Нәфис Косметикс» акционерлык җәмгыяте – М. Вахитов исемендәге Казан химия комбинатының (Крестовниковларның элеккеге 1 номерлы сабын һәм шәм заводы) 18 нче цехы кладовщигы **Габдрахманова** Мәймүнә Мәгъсүм кызы; банк системасын үстерү һәм камилләштерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «АК БАРС» акционерлык коммерциячел банкы (гавами акционерлык җәмгыяте) «Саба № 1» өстәмә офисының сатулар офисы җитәкчесе **Галиев** Исхак Галимҗан улы; халык сәламәтлеген саклау эшенә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Чаллы үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының медицина часте буенча урынбасары **Кукушкин** Иосиф Виссарионович; Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе урынбасары **Хуҗиева** Гөлсинә Мохтар кызы; законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклаудагы казанышлары, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы **Скирда** Максим Владимирович; республиканың төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Камстрой-НЧ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Фәйзуллин** Фәнис Нәҗип улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы буенча Җирләрне сугару һәм авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе филиалы – Тукай районы сугару-корыту системаларын эшләтү идарәсенең (СКСЭИ) әйдәүче мелиораторы **Шәвәлиева** Назирә Әсхәт кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«УПТК Татмелиорация» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең күперле кран кранчысы **Вәлиуллин** Миңнулла Һидиятулла улына, «ФАРТЭК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Гайнанов** Илфат Камил улына, Әлки районы «Мелиорация» күчмә механикалаштырылган колоннасы ачык акционерлык җәмгыяте экскаваторчысы **Гыйлаҗев** Фәргать Фәттах улына, «Ремсельбурвод» акционерлык җәмгыятенең бораулау җайланмасы машинисты **Гыйниятов** Тәлгать Әхәт улына, «Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте проект-смета идарәсенең проектлар бүлеге баш белгече **Иванова** Анна Ивановнага **«Татарстан Республикасының атказанган мелиораторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТӨЗЕЛЕШ һӘМ РЕМОНТ БРИГАДАСЫ
барлык төрдәге төзелеш эшләрен башкара
ЯЗГЫ ТАШЛАМАЛАР

Үзебезнең яки заказчының материалын кулланабыз.
Коймалар, терраса, фундамент, сайдинг, түбә эшләре, мунча, беседка, хуҗалык корылмалары, өй күтәрү, бүрәнәләрне алыштыру, отмостка, борыс имитациясе эшләре.
Пенсионерларга 15-20% ташлама!
Өйләрне блок-хаус белән тышлау эшләре һ.б.
Мөрәҗәгать иткән көнне үк киләбез!
тел.: 8 968 618 37 78, 8 905 199 99 79
Реклама

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест



ГАҖӘЕП ДӨНЬЯ

1. Кеше тәнендәге иң каты матдә.
А) теш;
Б) сөяк;
В) йөрәк.

2. Имезүчеләр семьялыгына кергән кайсы җәнлек оча белә?
А) бөркет;
Б) пингвин;
В) ярканат.

3. Планетадагы иң зур мәче?
А) арыслан;
Б) юлбарыс;
В) ак барс.

4. Салават күперендә ничә төс бар?
А) 10;
Б) 6;
В) 7.

5. Олы кешенең тәнендә сөякләрнең саны күпме?
А) 206;
Б) 105;
В) 501.

Җаваплар: 1) А; 2) В; 3) Б; 4) В; 5) А.

Ата-ана колагына

Кычкырма!

Кайчагында бик тәҗрибәле әти-әниләр дә «кызып» китәргә мөмкин. Әмма эчке ярсу балага кычкыруга кайтып калмасын иде. Бу нәрсәсе белән куркыныч?

Беренчедән, баланың үз-үзенә ышанычы кимергә мөмкин. Шул рәвешле «кечкенә кеше» синдромы барлыкка килүе ихтимал.

Икенчедән, агрессия агрессияне уята. Сездән күреп балагыз да ярсу, усал булмагае. Бу исә яшьтәшләре арасында мөнәсәбәтләр бозылуга, бәхәс, ызгышларга да китерергә мөмкин.

Өченчедән, балага кычкыру курку хисен арттырачак. Ягъни ул иң якын кешеләре – әти-әнисеннән шүрли башлаячак. Мондый басым астында яшәгән бала җәмгыятьтә дә югалып калырга мөмкин.

ӘМИНӘ ӘХМӘТҖАНОВА:

«ХАЛЫК ҖЫРЧЫСЫ БУЛЫРГА ТЕЛИМ»

Йөзендә елмаю, ә күзләрендә очкын балкый. Сәхнәдәге чыгышлары һәм моңлы тавышы белән күпләрнең күңеленә үтеп керде ул. Яшь булуына карамастан, күп бәйгеләрдә катнашып, җиңүләр дә яуларга өлгергән. Сүзебез – кечкенә йолдызчык Әминә ӘХМӘТҖАНОВА турында.

:: Әминә, ничә яшьтән җырлыйсың инде?
– Мин 6 яшемдә җырлый башладым. Башта Вафирә Гыйззәтуллина исемендәге 26 нчы номерлы музыка мәктәбенә йөрдем. Анда Камилә апа Гыйззәтуллинадан вокал дәресләре алдым. Шуннан соң төрле конкурсларда катнашып, җиңүләр яулый башладым. Шулай сәхнә мине үзенә гашыйк итте. Хәзер мин Чайковский исемендәге беренче музыка мәктәбендә укыйм. Сәхнәдә чыгышлар ясыйм.

:: Күбрәк нинди җырлар башкарасың?
– Татар халык җырларын бик яратып башкарам, инглиз телендә джаз стилендә җырлар ошый.

:: Сәхнәдә үзеңне ничек хис итәсең? Дулкынлану хисе бармы?
– Миңа сәхнәдә рәхәт. Баштарак аз гына дулкынлану хисе булса да, сәхнәгә чыккач, ул юкка чыга. Зал тулы булуын яратам, чөнки тамашачыларның күзләренә карап җырлау ошый.

:: Син күп кенә халыкара һәм илкүләм фестивальләрдә җиңүләр яулыйсың. Конкурсларда катнашу ошыймы үзеңә?
– Конкурсларда бик яратып катнашам. Аларны үзем эзләп табам, әнием белән гаризаны җибәрәбез. Конкурсларга вокал буенча укытучым – Татарстанның атказанган артисты Эльмира апа Кәлимуллина белән әзерләнәбез. Аның белән икенче ел шөгыльләнәм. Без аның белән бер-беребезне ярты сүздән аңлыйбыз.

:: Киләчәктә үзеңне җырчы итеп күрәсеңме?
– Әйе, тик мин җырчы гына түгел, халык җырчысы булырга телим. Кешеләрне бик яратам, үземнең иҗатым белән аларның күңелләренә үтеп керергә телим.

:: Әниең белән әтиең син сайлаган юлны хуплыйлармы?
– Әниемнең мине гимнастка итеп күрәсе килгән. Мин кечкенә чакта ул гел гимнастика белән шөгыльләнүче кызларга сокланып караган. Кызым булса, шул юлдан китәр, дип хыялланган. 5–6 яшьтә мин гимнастика һәм шул ук вакытта музыка белән шөгыльләнә башладым. Икесе дә – күп вакыт таләп итүче шөгыль, берсен сайларга кирәк иде. Җыр күңелемә якынрак булды. Хәзер әтием белән әнием минем уңышларыма сөенәләр, яраткан шөгылем булуыма бик шат алар.

:: Тагынниләр белән шөгыльләнәсең?
– Быел Гөлнара Качалованың актерлык осталыгы студиясенә йөри башладым. Биредә мин сүз осталыгы буенча шөгыльләнәм. Шуның белән «Созвездие – Йолдызлык» фестивалендә дә катнаштым. Шәһәр буенча беренче урынны алдым. Беренче ел өчен бу яхшы нәтиҗә дип уйлыйм. Әлеге юнәлеш миңа «Шаян ТВ»да тапшырулар алып барганга күрә дә ошый. Анда хәзер мин «Тиззарядка» тапшыруын алып барам. Телеканалга шундый зур тәҗрибә биргәне өчен мин бик рәхмәтле.

Кунагыбыз турында белешмә

✓ Әминәгә – 11 яшь;
✓ ул Казанның 116 нчы лицеенда 5 нче сыйныфта укый;
✓ җырлый, клипларда төшә, тапшырулар алып бара;
✓ халыкара һәм илкүләм конкурслар лауреаты, Казан мэры стипендиаты.

:: Барысына да ничек өлгерәсең? Буш вакытың каламы?
– Минем буш вакытым юк диярлек. Әнием миңа кайчак: «Әминә, әйдә бераз ял итеп тор», – дип әйтә. Тик минем тормышымның бер генә мөһим вакыйгасын да калдырасым килми. Буш вакытым булса, дусларым белән күрешәбез. Алар белән җырлыйбыз, фортепианода уйныйбыз, вакытны күңелле үткәрәбез.

:: Иҗат юлында синең өчен кем үрнәк булып тора?
– Безнең гаиләдә иҗат кешеләре күп. Дәү әнием – баян буенча, әтием скрипка буенча музыка мәктәбен бетергән. Роза әбием гел җырлый, бабай баянда уйный торган иде. Баянга кушылып, Әлфия Авзалованың җырларын бергәләп җырлыйлар иде. Мин үзем дә Әлфия Авзалованың җырларын тыңларга, аның элеккеге концертларын карарга яратам. Ул – минем өчен үрнәк. Миңа аның тавышы, тембры, репертуары ошый. Аның репертуарындагы җырларны бик рәхәтләнеп башкарам.

:: Уңышка ирешүнең сере нидә дип уйлыйсың?
– Уңышка ирешү өчен күп хезмәт, көч куярга туры килә. Һәрвакыт үзеңне камилләштерергә кирәк. Гел беренче булып булмый, билгеле. Андый очракларга тормышта кирәк булачак тәҗрибә дип карыйм.

:: Иң зур хыялың нинди?
– Мин барлык кешеләрнең озак яшәвен, һәрвакыт бергә булуларын телим. Әни бәлеш әзерләп, бөтен гаилә белән бергә өстәл янына җыелган вакытларны, туганнарымны бик яратам.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Балачак җыры

«Татар-информ»

Рәхәтләнеп җырлыйбыз! «Шаян ТВ» балалар телеканалы уздырган «Балачак җыры» бәйгесе быел да өр-яңа биш җыр бүләк итә. Ә өч ел эчендә җыйган җырлар барысы да махсус җыентыкка тупланачак. Җырларның фонограммасын, аларга төшерелгән матур видеоклипларны shayantv.ru сайтында табып булачак. Бу хакта тулырак сайттан укып белә аласыз.

Әкият

Тел югалту – ил югалту

Борын-борын заманда бик ерак бер авылда яшәгән, ди, бер ир белән бер хатын. Болар бик дус, тату булганнар. Тирә-яктагы кешеләр аларга карап сокланганнар. Аларның бер-бер артлы өч уллары туган. Уллары берсеннән-берсе уңган, тырыш, булдыклы булып үсеп тә җиткәннәр. Ата-аналары аларны туган җирләренә зур хөрмәт күрсәтергә, туган телләрен кадерләргә өйрәткән. Уллары аталары сүзеннән чыкмаган, һәрвакыт аңа тугры булганнар.

Еллар үткән, егетләр үз тормышларын корганнар, ди. Үз гаиләләрендә дә ата-аналарының өйрәткәннәрен истә тотып яшәргә тырышканнар. Вакытлары җиткәч, әти-әниләре бакыйлыкка күчкәннәр, ди. Уллары бик кайгырганнар, ләкин тормыш дәвам иткән.

Шулай матур итеп кенә яшәгәндә, кинәт бер кайгы-хәсрәт килгән. Күрше дәүләт башлыгының бу ерак, халкы бик тырыш һәм эшчән булган авылга күзе төшкән бит. Һәм ул бу авылга яу җибәргән. Озак көрәшкәннәр, ләкин көчләр тигез булмаган, авыл басып алынган. «Кем дә кем үз туган телен онытып, минекенә алмаштырса, минем дәүләтемдә урынын, сый-хөрмәтен табар», – дип әйткән чит дәүләт башлыгы. Барлык авыл халкы куркудан шул патшага буйсынган, ди, тик шул өч егет кенә ризалашмаганнар. Патшаның бик нык ачуы килгән инде, егетләрне янына чакыртып китерткән дә: «Ни өчен әле сез минем фәрманыма каршы киләсез, үзегезнекен генә түгел, гаиләләрегезнең дә башларын өздертәм бит хәзер», – дип әйткән, ди. Егетләр бертавыштан: «Безне кечкенәдән әти-әниләр кешеләрне хөрмәт итәргә, туган телне кадерләргә, туган җиребезне яратырга өйрәттеләр. Башларыбызны өздерсәгез өздерерсез, ләкин без аларга тугры булып калабыз», – дигәннәр. Шул сүзләргә, егетләрнең кыюлыгына, аларның ата-аналарына тугрылыгына патшаның исе киткән.

livejournal.com

Шул көннән егетләргә үз туган телләрендә сөйләшергә рөхсәт биргән.

«Тел бирмәк – җан бирмәк», – дигәндәй, егетләр үзләренең тәвәккәллекләре аркасында туган телләрен саклап калганнар.

Илдус МӘРДӘНОВ, 14 яшь,
«Глаголица» конкурсы җиңүчесе.
Чаллы шәһәре

Киңәш-табыш

Әдәпле шул кешедер...

– Бөекләр сөйләшкәндә сүзгә катышмагыз вә үзегезгә эндәшмәгәндә сүзгә кушылмагыз, сөйләшкән вакытыгызда артык сөйләшмәгез, бер сүзне күп мәртәбә кабатламагыз!

– Үз-үзегезне мактамагыз, үзегезгә кирәк булмаган сүзләргә катышмагыз, чит кешеләр серләрен тикшереп йөрмәгез, ике кеше сөйләшкәндә араларына барып кермәгез, үзегезгә әманәт ителгән серләрне шәригать рөхсәтеннән башка җирдә һич фаш итмәгез!

– Бер кеше өчен икенче бер кеше белән бозылышмагыз, ихтимал, алар дуслашырлар, сез исә уртада дошман булып калырсыз.

– Бер-берегездән көнләшмәгез, ачуланышмагыз, сүз үлчәшмәгез, бер-берегездән аерылып тормагыз. Ачу вакытында үз-үзегезне тота белегез.

– Гыйлем өйрәнү – бәндәләр өстендә олуг бурычтыр. Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре: «Белмәгән нәрсәләрегезне белгән кешеләрдән өйрәнегез!» – дип боерган. Һәм: «Белгән кешеләр белән белмәгән кешеләр бер дәрәҗәдә була алырмы? Булмаслар!» – дигән.

(Ризаэтдин ФӘХРЕТДИНнең «Әхлак гыйлеме» китабыннан)

Шаян хикәя

ФЕЯ БҮЛӘГЕ

Ильясның теше төште. Тиз генә төшмәде инде. Башта бераз авыртып торды. Ильяс сиздерми генә елап та алды хәтта. Теш малайны кызганды бугай. Алма ашаганда төште дә куйды. Ильяс нидер дөрес түгеллеген шундук сизенде. Караса, алмада аның теше тырпаеп тора. Менә сиңа мә!

Ильяс бик сөенде. Бүген төнлә бу тешне мендәр астына салып ятачак ул. Ә иртән торуына мендәр астында бүләк булачак. Теш җыя торган фея калдырачак ул бүләкне. Мультиктагыча. Теш чиста булса – бүләк шәбрәк. Шуңа төшкән тешен Ильяс щетка белән чистартып та куйды әле. Теш ялтырап тора!

Малай иртән уяну белән, кулын мендәр астына тыкты. Әһә! Нидер бар. Мендәрен алса, уенчык машина – зәп-зәңгәр «БМВ»!!! Ильяс, шатлыгыннан ура кычкырып, аш бүлмәсенә атылды.

– Әни, әни! Кара, фея миңа нинди бүләк калдырган!!!

Әнисе дә сөенде. Әтисе дә тел шартлатып куйды. Машина чыннан да шәп иде. Рәхмәт инде фея апага. Машинаны хәтта тартмадан чыгарып куйган бит мендәр астына. Ильяска каты булмасын дигәндер. Тартманы әтисенең сумкасына яшергән менә. Хәйләкәр фея!

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7057 данә
Гомуми тираж – 16016 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 278

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+